ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.11.2021 Казан ш. № 325-62/тэ-2021

«ТеплоЭнергоСнабжение» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җылылык белән тәэмин итүче, җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 27.11.2019 № 5-71/тэ карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2022 ел өчен үзгәрешләр кертү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя куюу турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә һәм 2022 елга җылылык энергиясе югалуны компенсацияләү максатында җылылык энергиясе сатып ала торган җылылык челтәрләре оешмаларына, җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) 2022 елга җайга салынулы оешманың планлаштырылган кирәкле тулай керемен тәгаенләштереп, озак сроклы тарифларны төзәтү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «ТеплоЭнергоСнабжение» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җылылык белән тәэмин итүче, җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2020-2022 елларга тарифлар билгеләү турында» 27.11.2019 №5-71/тэ карарының (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2020 №407-67/тэ-2020 карары

нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтасына, аны яңа редакциядә биреп (кушымтада бирелә), үзгәреш кертергә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л. Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
27.11.2019 № 5-71/тэ карарына
кушымта (Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
19.11.2021 № 325-62/тэ-2021
карары редакциясендә)

## «ТеплоЭнергоСнабжение» ҖЧҖ тарафыннан җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга, җылылык энергиясен югалтуларны компенсацияләү максатында җылылык энергиясен сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2020-2022 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланган пар | | | | Әче һәм редукцияләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | Казан шәһәре | | | | | | | |
| 1 | «ТеплоЭнергоСнабжение» ҖЧҖ* | | | | | | | |
| 1.1 | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 1290,49 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 1322,29 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 1322,29 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 1368,32 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 1368,32 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 1423,11 | - | - | - | - | - |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге